**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-81.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (территорияне коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү, башка төр эшләр);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Родничная урамындагы юлларны чокырларга ремонтлау һәм вак таш белән каплау; Яңа Елховой авылының Родничная урамындагы юлларны кардан чистарту) .

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк ур., 4 й.; Яңа Елховой ав., Чишмә ур., 22 й.; Бохар авылы Авангард ур., 23 й., Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Урмышлы авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Хәбибуллин